**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Кариле авыл җирлеге Чаллы авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**03 декабрь 2024 ел** **№4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 03 декабрендә 10.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Чаллы авылында 2025 елда авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә ризамы:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 102 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 52 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

позиция өчен-52 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде;

каршы позиция өчен - 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Чаллы авылында гражданнар җыенын үткәрелгән дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны : «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлеге Чаллы авылында 2025 елда авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерүгә ризамы:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.», кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерү:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер ур., 1;

- ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин ур., 43;

-ТР, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов ур., 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Кариле
авыл җирлеге башлыгы: Ф.Г. Гарифуллин